# Гыйззетдинова (Мөхәмміткәшипова) Розания Мөхәмміткәшип кызы



1941 елның 10 сентябрендә Мәртен авылында туа. Мәртен башлангыч мәктәбендә белем ала. 16 яшендә 1957 елда колхоз члены була.

1969 елны Юлбат авылына килен булып төшә. 4 бала тәрбияләп үстерәләр. Лаеклы ялга чыкканчы колхозда төрле эшләрдә хезмәт куя. 2015 елның 15 августында 73 яшендә бакыйлыкка күчә.

# Гыйззетдинов Сөләймән Гыйззетдин улы



1937 елның 26 мартында Юлбат авылында туа. Юлбат башлангыч мәктәбендә 4 класс белем ала. Сугыш еллары булу сәбәпле, яшьтән төрле авырлыклар белән көрәшеп эшләп үсәргә туры килә.

1957 елны Чиләбе өлкәсенә армия хезмәтенә алына. Шул вакытта “Маяк” радиактив станциясендә зур авария була. Анда катнашып сәламәтлегенә зур зыян килә.

1969 нчы елны Мәртен авылының Мөхәмміткәшип кызы Розания белән тормыш корып җибәрәләр. 4 бала тәрбияләп үстерәләр. Лаеклы ялга чыкканчы колхозда хезмәт куя. 25 ел терлекчелектә эшли.

1999 елның 16 июлендә 62 яшендә бакыйлыкка күчә.



# Төхбәтуллин Даниял Төхбәтулла улы

1940 елда Юлбат авылында туа. Юлбат башлангыч, Сатыш җидееллык мәктәбен тәмамлый. 1962 елда, армиядән кайткач, механизаторлыкка укый. 1965 елдан лаеклы ялга чыкканчы колхозда тракторда эшли. Эш дәверендә тыныч холыклы, ярдәмчел, сабыр булуы белән аерылып тора. Тырыш хезмәте өчен **“Почет билгесе” ордены белән бүләкләнә, 1986 елда “Татарстанның атказанган механизаторы” дигән мактаулы исем бирелә.** Тормыш иптәше Вәсилә апа белән 3 бала тәрбияләп үстерделәр. Бүгенгесе көндә вафат.



# Билалова (Гыйззетдинова) Сания Гыйззетдин кызы

1939 елның 25 октябрендә Юлбат авылында туа. Юлбат мәктәбендә 4 еллык белем ала, 7 классны Сатыш мәктәбенә йөреп тәмамлый. Эш юлын колхозда башлый, шул эшенә тугры калып пенсия яшенә кадәр гади колхозчы булып эшли. Эштә сынатмый. 1968 елда тормышын шушы авыл егете Билалов Данил белән бәйли. Ике кыз тәрбияләп үстерәләр. Сугыш вакытында әниләре Миңзифа 4 бала белән калган. **Әтиләренең сугышта “хәбәрсез югалды” дигән язуын алганнар.** Сания Гиззетдин кызы 2016 елның 16 апрелендә вафат булды.



# Хужин Авангард Гобәй улы



1940 елның 14 маенда Юлбат авылында туа. Сугыш чорын хәтерләми иде. Сугыш вакытында алар 4 бала булганнар. 4 класс белеме бар. 1959 елның ноябрендә Совет Армиясе сафларына алына. 1962 елда армиядән кайткач колзозга эшкә урнаша. 1987 елда янгын сүндерүчегә укып кайта. Озак еллар колхозда тырыш хезмәт куя.

1963 елда Тәгъзимә Фәрхетдин кызы белән тормыш корып җибәрәләр. Алар 5 бала: 3 малай, 2 кыз тәрбияләп үстерәләр. 2016 елда вафат булды.



# Кәримов Рифкат Кәрим улы

1940 елның 19 октябрендә Юлбат авылында туган. Сугыш вакытында гаиләдә 5 бала булган. **Әтисе сугышта хәбәрсез югалган.** Шофер булып, соңгы елларда колхозда эшләгән. Гомеренең күп вакытын балта остасы булып хезмәт куйган. Юлбат авылы кызы Раушания белән тормыш корып 3 бала тәрбияләп үстергәннәр.

2014 елның 29 октябренда вафат булган.




# Галимуллин Рәҗәб
# Миннегали улы

1939 елның 7 сентябрындә Саба районы Калатау авылында туган. Иң истә калган вакыйга: 3 яшендә матчага кыстырылган әтисенең соңгы килгән хатын һәм фотосын алып, бакчага кереп, кайчы белән кисә. Гаиләдә 2 бала булганнар.

**Әтисе хәбәрсез югалган.** Ул колхозда электрик булып 22 ел эшли. Эшләгән өчен бик куп мактау грамоталары бар. Юлбат кызы Мәшүдә белән 3 бала тәрбияләп үстерәләр. Калатау авылында гомер итеп 2016 елның 8 апрелендә 77 яшендә вафат булды.

# Хуҗин Габделхәй
# Ахун улы

1938 елның 7 июлендә Югары Шытсу авылында туган. **Әтисе Ахун сугышта үлеп калган.** Әнисенә берсеннән берсе 3 малай калганнар. Көтүләр көтеп, ачлы-туклы бик авырлык белән яшәгәннәр. Габделхай абый пенсиягә чыкканчы фермада маллар карап, скотник булып эшләгән. 2016 елда вафат булды.



# Мәҗитова (Фәрхетдинова) Саимә Фәрхетдин кызы

1936 елның 30 сентябрендә Юлбат авылында туа. Әтисе, Фәрхуллин Фәрхетдин Фәрхулла улы, **1941 елның 25нче августында сугышка китә. 1945 нче елның сентябрендә демобилизацияләнеп туган авылына кайта.** Сугышта алган яралар аңа озак яшәргә бирми,1957 елның 8 мартында вафат була. Әнисе,Фәрхиева Хәтирә, ире сугышка киткәндә 5 яшьлек Саимә һәм 1 яшьлек Тәгъзимә кызлары белән кала.Әниләре урман кисүдә окоп казуда, барлык авыр эшләрдә эшләгәндә, кечкенә сеңлесенә күз-колак булырга кирәк була узе дә әле сабый гына булган Саимәгә.

1960 елда кияүгә чыга, ире Мәҗитов Йофар белән өч ул, бер кыз үстерәләр. 1996 елга кадәр колхозда терлекләр карап лаеклы ялга чыга.

Тырыш хезмәтләре өчен ул бик күп мактау кәгазъләре, рәхмәт хатларына лаек була. **Казан шәһәрендә үткәрелгән терлекчеләр съездына делегат була. 1975 елда “Ударник девятой пятилетки”, 1980 елда “Ударник десятой пятилетки” медальләре белән бүләкләнә.**

2005 елның 5 февралендә вафат була.



# Мәҗитов Йофар Мәҗит улы

1935 елның  23 декабрендә Юлбат авылында туа. **Әтисе Мотыйков  Мәҗит 1941 елның 14 августында сугышка китә, тик бер хаты да килми, хәбәрсез югала.**
Әнисе, Мотыйкова Әминә, 6 яшьлек Йофар һәм  2 яшьлек Ягъфәр исемле уллары белән  сугыш  чоры елларының барлык авырлыкларын үз җилкәләрендә күтәрә. Сугыш чоры елларында кычыткан, черек бәрәңге алабута ашауларын, “уфалла”, тартып өйләренә ягарга утын алып кайтуларын бик дулкынланып сөйли торган була ул. Ул елларда утлы
күмерләрне сундермичә саклап, авыл халкына бик зур ярдәме тигән Хәмдениса әбиләрен әле дә бик хөрмәтләп искә ала авылның өлкән кешеләре.

1954-1957 елларда армия сафларында  Германиядә хезмәт итә. Аннан кайткач өйләнә. Хатыны Мәҗитова Саимә белән өч ул, бер кыз үстерәләр. Колхозда тракторист, кочегар, терлекче булып эшләп 1995 елда лаеклы ялга чыга.

Хезмәтләрен хөрмәтләп ул **1975 елда “Победитель социалистического соревнования 1974 года” медале, 1976 елда “Ударник девятой пятилетки” медале, 1981 елда ВДНХ СССРның “За достигнутые успехи в развитии народного хозяйства СССР” бронза медале**  һәм башка мактау кәгазьләре, рәхмәт хатлары белән бүләкләнә. 2015 елның 5 июлендә вафат була.



# Каримова (Миңнебаева) Сажидә Йосыф кызы

1939 елның 10 январендә Чирмешән районы Түбән Чегодайка авылында туган. Гаиләдә 8 бала дөньяга килә. **Әтисе Бөек Ватан сугышында катнашып, 1944 елда вафат була.** Сугышта ике абыйсы да катнаша. Белеме 7 класс. 7 классны тәмамлауга заводта эшләгән. Аннан соң сарык, бозау караган, сыер сауган. 1974, 1982, 1985 елларда “Победитель социалистического соревнования», 1979 елда «Ана даны» медальләре белән бүләкләнә. Тенеки егетенә кияүгә чыгып 5 бала: 4 малай, 1 кыз тәрбияләп үстерәләр. Хәзерге көнгә кадәр Тенеки авылында яшәде. 2016 елның 11 августында вафат булды.



# Ибраһимова (Закирҗанова)
# Рафига Закирҗан кызы

Ибраһимова (Закирҗанова) Рафига Закирҗан кызы 1940 елның 10 июнендә Саба районы Юлбат авылында Әхмәтҗанов Закирҗан һәм Хөсникамал гаиләсендә дүртенча бала булып туган. Игез сыңары Нафига ике айлык вакытта үлә. 1941 елда сугышка киткән әтиләре Закирҗанның 1942 елда хәбәрсез югалуы турында хәбәр килә. Әниләре 4 бала белән тол кала. Мәктәптән соң Рафига апасы Саймә янына китеп Кукмарада тегү фабрикасында тегүче, итек фабрикасында тәрбияче булып эшли. Юлбат авылы егете Мөхәмәтәмин белән гаилә корып бер ул, ике кыз тәрбияләп үстерделәр. Мәктәп интернатында тәрбияче булып эшләп лаеклы ялга чыкты. 2011 елның 2 январендә вафат булды.

# Ибраһимов Әмин Ибраһим улы

1940 елның 13 августында Саба районы Юлбат авылында Сәләхов Ибраһим һәм Гайниҗамал гаиләсендә беренче бала булып туган. Әтисе 1944 елда сугышка алынган. 1945 елда сугыштан исән-сау әйләнеп кайткан. Сугыштан соң ике малай, бер кыз туган. Бер ир туганнары кечкенә вакытта үлгән. Мөхәмәтәмин өлкәннәргә ияреп яшьтән өязгә чыгып итек баскан, балта эшенә өйрәнеп, йортлар салган. Бик күп еллар пилорамада эшләде. Мәктәптә газ опрераторы, тегермәндә тегермәнче булып эшләп лаеклы ялга чыкты. Рафига белән гаилә корып бер ул, ике кыз тәрбияләп үстерделәр. 2015 елның 28 февралендә вафат булды.

# Мөбәрәкҗанов Рәис Мөбәрәкҗан улы



Туган елы: 1935 ел 3 нче март

Туган җире: Юлбат авылы

“Мин 4 класслык башлангыч белем алдым. 1947 елдан Сатыш авылына җидееллык мәктәпкә йөрдем. 1951 елда Тәтеш берьеллык авыл-хуҗалыгы мәктәбендә белем алдым. 1944 елда әнине Шәмәрдәнгә урман кисәргә җибәрделәр. Шул ук елны март ахырында әти, аягы яраланып, контузия алып, култык таякларында туган нигезенә кайтып егылды. Ни өчен кайтып егылды дим, чөнки ул үзе генә кайта да ала торган хәлдә түгел иде. Аны госпитальдән озатып бер санитар кыз кайтарып куйды. Ярый әле аларга Шәмәрдән станциясендә җигүле ат белән авылдашлар очраган. Шуларга утырып кайтканнар...

Безнең балачак авыр сугыш елларына туры килде.Сугышның ачысы барыбызга да эләкте, бу дәһшәтле елларның афәтен һәр гаилә кичерде. Олыны да, кечене дә аямады ул.  Күп аналар тол калды, сөйгәннәрен, улларын һәм кызларын югалттылар. Таза ир-атларны сугышка алдылар, авылда эшләрдәй кеше калмады. Бөтен эш бала-чагага, карт-корыга калды. Сугыш чорында нинди авыр эш туры килде, барсын да эшләдек. Ул елларда колхоз күп яшелчә үстерә иде. Яшелчәлек бакча башында гына булганга, мине һәм Равиль энемне яшелчә сакларга куйдылар. Казларны хуҗалары, эшкә киткәнче, бик иртә су буена озаталар. Казлар бик хитрыйлар, су буйлап яр кырыеннан, яшелчә бакчасына керәләр. Без казлар кермәсен дип, талдан читәннәр үреп куйдык һәм Фокс исемле овчарка көчеге алып, аны казларны куырга өйрәттек. Иң кыены шул, әни безне шул казларны куарга бик иртә уята һәм без яланаяклап, иртәнге салкын чыклы үлән өстеннән, каз куарга йөгерә идек, чөнки ул вакытта аякка кияргә бутый да, галош та юк иде.

Әткәй сугышта алган яраларыннан терелә алмады, 1949 елның 1 нче июнендә вафат булды. 1954 елда кладовщик булып эшкә кердем. 1954 елның 12 нче октябрендә армиягә алындым. Ленинград өлкәсе Пушкин шәһәрендә бер ел телефонографистлыкка укыдым. Северский посёлогындагы авиация частында радиотелефонографист булып хезмәт иттем. 3ел да 2 ай хезмәт итеп, туган авылга исән-сау әйләнеп кайттым. Кайткач Мамадышта 6 ай шофёрларар әзерләү курсында укыдым. 1960 елда курсларны уңышлы тәмамлап, шофёр правасы алып, туган авылымда ГАЗ-51 машинасында эшли башладым. Мин 40 елдан артык шофёр булып эшләдем. Ул еллардагы авырлыкларны хәзер искә төшерәсе килми. Эшләү дәверендә өч машина алыштырдым. Бик күп тапкыр мактау грамоталары белән бүләкләндем.

1968 елда безнең авылга Зеленодольский районы Карауҗа авылыннан бик чибәр фельдшер кыз Фәридә эшкә килде. Аның белән танышып, дуслашып йөреп, бергә гаилә кордык. Без ике кыз һәм бер малай тәрбияләп үстердек. Улым минем эшемне дәвам итүче – шофер булып эшли. Бар теләгем : без күргәннәрне хәзерге буын балалар һәм оныклар күрмәсеннәр иде.”,- дип сүзен тәмамлады.

Дәү Әтием авылның хөрмәтле кешесе булып, 79 яшенә кадәр улы гаиләсе белән тату, матур гомер кичерде.

Оныгы Мөбәрәкҗанов  Айрат  Ленар улы.



## Закирҗанов Зариф
## Закирҗан улы

1932 елның 23 январендә  Саба районы Юлбат авылында Әхмәтҗанов Закирҗан һәм Хөсникамал гаиләсендә икенче бала булып туган. Хуҗалыкта көче җиткән эшләрне башкара. Сугыштан соң почта йөртә. Атлар карый. 1981 елда гаиләсе белән Дәрвишләр бистәсенә күчеп китә. Анда киткәч балалар бакчасында эшли. Кыз һәм ул үстерделәр. 1993 елның ноябрендә вафат булды.

## Мингафарова (Закирҗанова)
## Найлә Закирҗан кызы

1935 елның 3 мартында Саба районы Юлбат авылында Әхмәтҗанов Закирҗан һәм Хөсникамал гаиләсендә өченче бала булып туган. Кечкенә сеңлесен карау аның өстендә була. Үскәч Кемерово шәһәренә эшкә китә. Шунда тормышка чыга. Тормыш иптәше белән кыз һәм ул тәрбияләп үстерделәр. Хәзергесе вакытта Нократ Аланында яши.



# Шәмсиев Рәшит Шәмси улы


1932 елның 28 августында Юлбат авылында Гомәров Шәмси белән Зәйнәп гаиләсендә икенче бала булып дөньяга туа. Рәшит бабайның балачагы дәһшәтле сугыш чорына туры килә. Сугыш башланганда Рәшит бабайга 9, абыйсы Һарун бабайга 10 яшь була. **1942 елда әтиләре - Шәмси бабай хәбәрсез югала.** Әтисез ятимлектә үскән ике ир туган тормышта сынатмыйлар. 1951 - 1954 елларда Рәшит бабай Совет Армиясе сафларында хезмәт итә. 1963 елда Флера әби белән гаилә коралар. Рәшит бабай “Искра ”колхозында төзүчеләр бригадиры, балта остасы булып эшли. 1962 елда, хәзерге Райпо кибете, 1967 елда сугышта һәлак булганнарга һәйкәл, амбарда икмәк складлары, сыер фермалары һәм бик күп төзелеш эшләрендә катнаша. Ләкин каты авырудан 1982 елда вафат була. Рәшит бабай турындагы хәтирәләр әбием Флера сөйләве буенча язылып алында.

Оныгы Шәмсиева Талия Талип кызы.



## Рахматуллин
## Камил
## Рахматулла улы

27.09.1936 - 22.09.2007
**Юлбат авылына җирләнгән.**



## Заһретдинов
## Гыйлметдин
## Заһретдин улы

17.12.1938 - 17.01.2013
**Юлбат авылына җирләнгән.**



## Заһретдинова
## Тәнзилә
## Рахматулла кызы

10.04.1939 - 01.04.2015
**Юлбат авылына җирләнгән.**

Сугыш чоры балалары.
Балачакны йоткан дәһшәт.
Җилкәләрдә–авыр хезмәт,
Янәшәдә–үлем, вәхшәт.

Ә аларга бары ун яшь,
Иң зурына унөчтер, шәт.
Тубыгына кадәр җитә
Атасыннан калган бишмәт.

Тегәр җептәй ябык куллар
Сабан сөрә, урман кисә.
Түзә ачлык-хезмәтенә,
Тик әтисе булсын исән!

Бик күптәннән хәбәре юк,
Ә сугышның кызган мәле.
Уң күршедә– яман кәгазь,
Сулда–билгесезлек хәле.

Сугыш чоры балалары,
Әниләрен хәвеф өтә:
Күзгә күренеп сулыгалар
Фронттан хат көтә-көтә.

Өчпочмаклы ул хатларда
Агу яки бәлзәм көче.
Хат ташучы күңелендә
Таштайката халык үче.

Ә сабыйлар оныта бара
Икмәк исен, токмач исен.
Тилмертмәсен иде ачлык
Бәгырьләрен кисеп-кисеп!

Еламасын иде ана
Яшерен генә, сулкып кына.
Кайчан кайтыр әтиләре,
Кайчан канлы дәһшәт тынар?

Сабыйларның хыяллары
Көнаралаш төшкә керә:
Әнә, солдат киеменнән
Әтиләре кайтып килә!

Кочып алып нәни кызын
Күтәрә дә күккә чөя.
Шатлыгыннан улы башы
Җирдән торып күккә тия!

Аерыласылары килми
Сабыйларның татлы төштән.
Өйдә-салкын, ашарга юк,
Әниләре көн-төн эштә...

Бик күбесе төштә генә
Әтиләрен күрә алды.
Бәхет солдат мәете булып
Яу кырында ятып калды.

Сугыш чоры балалары,
Наз күрмәгән боек күңел.
Ул елларда күргәннәрен
Онытырга мөмкин түгел.

Авыр төер булып яши
Китек күңел почмагында.
Гомер үткән ата түгел,
Кырыс тормыш кочагында.

Балачаксыз үскән буын–
Ул сугышның хөкемдары.
Кулларында–ал канәфер,
Җаннарында–канлы яра.
Әтиләре рухы өчен
Таш һәйкәлгә чәчәк сала...







**Бу альбомны Юлбат төп мәктәбе коллективы башкарды, 2017 ел.**